КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 16 апрель г.Казань № 252

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2014 ел, 12 апрель, 234 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты мәсьәләләре» 2014 ел, 12 апрель, 234 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 15 гыйнвар, 9 нчы; 2016 ел, 15 август, 565 нче; 2016 ел, 16 сентябрь, 648 нче; 2017 ел, 21 март, 171 нче; 2017 ел, 31 май, 327 нче; 2017 ел, 18 сентябрь, 680 нче; 2017 ел, 10 октябрь, 784 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты турындагы нигезләмә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3.2 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Архив эше белән идарә итү функциясен гамәлгә ашырганда Татарстан Республикасының Архив эше буенча дәүләт комитеты (01.15.03<*>).»;

4.1 пунктның егерменче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

4.2 пунктның икенче абзацында «туризмны үстерү стратегияләрен» сүзләрен «туризм өлкәсендә стратегик планлаштыру документларын» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин